| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.08.2019 Казан ш. № 7-6/т

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында

«Автомобиль транспорты һәм җир өсте шәһәр электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законны тормышка ашыру хакында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән чик дәрәҗә максималь тарифлар карар үз көченә кергәннән башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында» 02.12.2016 № 7-19/т карарын көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.08.2019 № 7-6/т карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча муниципаль маршрутларда автомобиль транспортында даими рәвештә пассажир һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Транспорт төре | Бер мәртәбә бару һәм бер урынга исәпләнгән багажны алып бару өчен чик дәрәҗәдәге максималь тариф (сум) | | |
|---|---|---|---|
| | билетны акчага сатып алганда | билетны түләү (банк) карталары яки башка төрле электрон түләү чаралары ярдәмендә, бәйләнешсез түләү технологиясе белән сатып алганда | юлга 100 һәм аннан күбрәк мәртәбә бару өчен дәвамлы файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә[1] |
| автобус | 18 | 18 | 18 |

<1> юл өчен пассажир йөртү һәм багаж ташуның даими муниципаль маршрутлары буенча гомуми файдаланудагы транспортта барган өчен күрсәтелгән срок эчендә билгеләнгән күләмдә бару хокукын бирә торган озак файдаланыла торган билет белән түләгәндә.

Искәрмә. Багажны алып бару бәясен түләү юл бәясен түләүдән аерым гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге